Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге составына керүче
Туйма авылында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

27 ноября 2023 года №
1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Туйма авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында " хисап комиссиясенең 2023 елның 27 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, ә 1 төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорауга карарны кабул итәргә
1. Вахитов урамындагы юлны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
2. юлларны кардан чистарту.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә

Халык җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Е.Ю.Скворцова